КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 26 апрель

г.Казань

№ 278

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән объектларны дәүләт милкендә яки муниципаль милектә булган җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә, җир кишәрлекләре бирмичә һәм сервитутлар, ачык сервитут билгеләмичә урнаштыру тәртибен һәм шартларын раслау турында» 2015 ел, 5 июнь, 416 нчы карары белән расланган Төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән объектларны дәүләт милкендә яки муниципаль милектә булган җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә, җир кишәрлекләре бирмичә һәм сервитутлар, ачык сервитут билгеләмичә урнаштыру тәртибенә һәм шартларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән объектларны дәүләт милкендә яки муниципаль милектә булган җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә, җир кишәрлекләре бирмичә һәм сервитутлар, ачык сервитут билгеләмичә урнаштыру тәртибен һәм шартларын раслау турында» 2015 ел, 5 июнь, 416 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 19 июнь, 393 нче; 2018 ел, 3 август, 631 нче; 2018 ел, 17 декабрь, 1152 нче; 2020 ел, 30 декабрь, 1227 нче; 2021 ел, 19 июль, 587 нче; 2021 ел, 31 август, 791 нче, 2021 ел, 12 ноябрь, 1065 нче, 2022 ел, 18 гыйнвар, 22 нче, 2022 ел, 14 апрель, 355 нче, 2023 ел, 22 сентябрь, 1175 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Төрләре Россия Федерациясе

Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән объектларны дәүләт милкендә яки муниципаль милектә булган җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә, җир кишәрлекләре бирмичә һәм сервитутлар, ачык сервитут билгеләмичә урнаштыру тәртибенә һәм шартларына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктта:

өченче абзацта «мөрәҗәгать итүче күрсәткән» сүзләрен «объектларны урнаштыруга рөхсәт бирү турындагы гаризада күрсәтелгән (алга таба - гариза)» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «Татарстан Республикасында җирлекләрнең, шәһәр округларының җирле үзидарә органы тарафыннан раслана торган велопарклар урнаштыру схемасы нигезендә урнаштыру өчен рөхсәт таләп ителми торган велосипедлар, роликлар, самокатолар һәм башка спорт инвентаре прокаты пунктларын урнаштыру схемасы нигезендә» сүзләрен «урнаштыру өчен төзелешкә рөхсәт таләп ителми торган велосипедларны, индивидуаль мобильлек чараларын, төрле спорт инвентарьларын кую һәм (яисә) саклау (урнаштыру) өчен билгеләнгән Татарстан Республикасы җирлекләрнең һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары тарафыннан раслана торган вакытлыча корылмалар һәм (яисә) вакытлы конструкцияләр урнаштыру схемалары нигезендә мондый корылмалар һәм (яисә) конструкцияләр чикләрендә» сүзләренә алмаштырырга»;

түбәндәге эчтәлекле 41  пункт өстәргә:

«$4^1$. Объектларны урнаштырган өчен түләү кертүдән федераль башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары, Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары тарафыннан төзелгән муниципаль учреждениеләр азат ителә.»;

7 пунктта «объектларны урнаштыруга рөхсәт бирү турында (алга таба - гариза)» сүзләрен төшереп калдырырга;

13 пунктта:

«а» пунктчасында «гариза бирүче» сүзләрен «зат» сүзенә алмаштырырга;

«е» пунктчасында «гариза бирүче» сүзләрен «зат» сүзенә алмаштырырга;

14 пунктның «з» пунктчасында «төзелешкә рөхсәт таләп ителми торган велосипедлар, роликлар, самокатолар һәм башка спорт инвентарьлары прокаты пунктлары, шулай ук велопарклар» сүзләрен «урнаштыру өчен рөхсәт таләп ителми торган корылмалар һәм (яисә) вакытлыча конструкцияләр чикләрендә велосипедларны, индивидуаль мобиль чараларны, төрле спорт инвентарен кую һәм (яисә) саклау (урнаштыру) өчен билгеләнгән вакытлыча корылмалар һәм (яисә) вакытлыча конструкцияләр» сүзләренә алмаштырырга;

16 пунктта:

беренче абзацта «Гариза бирүче» сүзләрен «объектларны урнаштыруга рөхсәт алган зат,» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта «Гариза бирүче» сүзләрен «объектларны урнаштыруга рөхсәт алган зат,» сүзләренә алмаштырырга;

18 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

19 пунктта:

икенче абзацта «тиешле муниципаль берәмлек» сүзләреннән соң «бюджет» сүзен төшереп калдырырга;

өченче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

191 пунктның икенче җөмләсен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле 21 - 23 пунктлар өстәргә:

«21. Вәкаләтле орган түбәндәге очракларда объектларны урнаштыруга рөхсәт гамәлдә булуын вакытыннан алда туктату турында карар кабул итә:

әгәр объектларны урнаштыруга рөхсәт алган зат тарафыннан җирдән яисә җир кишәрлегеннән файдалануны туктату турында ирекле рәвештә төзелгән гариза бирелгән булса;

әгәр объектларны урнаштыруга рөхсәт алган зат объектларны урнаштыру өчен түләү рәттән ике сроктан артык кертелмәгән булса;

объектны урнаштыруга рөхсәт алган затны халыкның санитар-эпидемиологик иминлеген тәэмин итү өлкәсендә административ хокук бозулар, территорияне төзекләндерү өлкәсендә административ хокук бозулар, әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигатьтән файдалану өлкәсендә административ хокук бозулар өчен административ җаваплылыкка тарту турында законлы көченә кергән карар булса;

вәкаләтле орган тарафыннан, Россия Федерациясе Җир кодексының 3936 статьясындагы 4 пунктында каралган очрактан тыш, гражданга яисә юридик затка җир кишәрлеге бирү турында карар кабул итү;

стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасына кертелгән стационар булмаган сәүдә объектын җир кишәрлегендә урнаштыруга шартнамә төзү;

дәүләт яисә муниципаль ихтыяҗлар өчен җир кишәрлеген алу;

объектларны урнаштыруга рөхсәт алган зат тарафыннан җирләрдән яисә җир кишәрлегеннән файдалану, объектларны урнаштыруга рөхсәткә күрсәтелгәннәрдән аерылып торган объектларны урнаштыру өчен.

22. Объектларны урнаштыруга рөхсәтнең гамәлдә булуын вакытыннан алда туктату турындагы карар вәкаләтле орган тарафыннан әлеге Тәртипнең 21 пунктында күрсәтелгән очрак барлыкка килү турында мәгълүмат алган көннән алып 10 эш көне эчендә кабул ителә.

23. Вәкаләтле орган объектларны урнаштыру рөхсәтен туктату турында карар кабул ителгән көннән алып 10 эш көне эчендә, язмача рәвештә почта аша, тапшыру турында хәбәрнамә белән объектларны урнаштыруга рөхсәт алган затка кабул ителгән карар турында хәбәр итә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин